РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСАЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**
№ 34 от 15.11.2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы Усали авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы « Усали авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Усали авыл җирлеге гражданнарының 2019 нчы елның 12 ноябрендә кабул ителгән 1 нче номерлы «Дружба поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче гражданнар җыены нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Усали авыл җирлеге гражданнарының 2019 нчы елның 12 ноябрендә кабул ителгән «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче Дружба авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы» җыеннар карарларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 елның 12 ноябрендә 2 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче Күк-Чишмә авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»,

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 елның 12 ноябрендә 3 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче Бөрсет-Сукачы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 елның 13 ноябрендә 4 нче санлы санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче Владимир авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 елның 13 ноябрендә 5 нче санлы санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче Югары Кыерлы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 елның 14 ноябрендә 6 нче санлы санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче Усали авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты;

К а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Усали авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге Советы рәисе /А.И.Зиатдинов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге
Башкарма комитетының 15
ноябрь 2019 ел, 34 санлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Усали авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Усали авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2020 елның 26 мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, житкерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль

районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге
Башкарма комитетының 15
ноябрь 2019 ел, 34 санлы
карарына 2 нче кушымта

_______________________
*(муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________________
Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең __________ авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2020 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 2020 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ______ сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:
___________________________________________________
Кабул итүче як банкы БИК _______________________________________
Сч. № ___________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ______________________________________
ИНН ______________________________________
КПП ___________________________________________
КБК _______________ ОКАТО ________________
Түләүнең билгеләнеше
Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче _________________ _________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - -**

_______________________________________________________________
*(муниципаль берәмлек исеме)*

________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.

____________________________________________________________

Адрес:

____________________________________________________________

_____

«__» ________________ 20__ г. ________________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегү шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)___________________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тотырыла һәм кала.*